КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 июль 827

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше күренешенә килештерү алу тәртибе турында» 2023 ел, 23 февраль, 177 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер боерыклары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше күренешенә килештерү алу тәртибе турында» 023 ел, 23 февраль, 177 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 1 июлендәге 275-ФЗ номерлы» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацы үз көчен югалткан дип тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 6 өлеше» сүзләрен өстәргә;

беренче абзацта «2023 елның 1 мартына кадәр» сүзләрен «2023 елның 1 сентябренә кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 21 ноябрь, б-2698 нче; 2023 ел, 1 март, б-534 нче боерыклары 2023 елның 1 сентябреннән үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин